**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

20.03.2023 ел. № 296-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 1 июлендәге 456-п номерлы боерыгының 3 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (А.С.Столповская) боерык күчермәсен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган көннән алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә җибәрергә, ә соңыннан, аңа үзгәрешләр кертелгәндә, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә төгәлләнгән исемлекне тапшырырга.».

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2016 елның 21 мартындагы 242-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2018 елның 15 февралендәге 137-п номерлы, 2022 елның 23 ноябрендәге 1111-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, әлеге нигезләмәгә, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) актларына таянып эш итә.»;

2.2 пунктның «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

2.3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 июлендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә Министрлык каршында төзелгән иҗтимагый совет вәкиле;»;

2.4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 17 августындагы 770-п номерлы боерыгының (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2016 елның 3 октябрендәге 1007-п номерлы, 2018 елның 20 мартындагы 233-п номерлы, 2019 елның 4 февралендәге 84-п номерлы, 2019 елның 19 ноябрендәге 1266-п номерлы, 2020 елның 12 октябрендәге 1127-п номерлы, 2021 елның 25 ноябрендәге 1301-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (А.С.Столповская) боерык күчермәсен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган көннән алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә җибәрергә, ә соңыннан, аңа үзгәрешләр кертелгәндә, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә төгәлләнгән исемлекне тапшырырга.».

4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмә раслау хакында» 2021 20 апрелендәге 412-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы

вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.8 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.12.3 пунктының икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.12.3 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тест уздыру Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнарга тест үткәрү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков